КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 19 июль г.Казань № 593

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларын раслау турында» 2013 ел, 27 декабрь, 1071 нче карары белән расланган шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларын раслау турында» 2013 ел, 27 декабрь, 1071 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 28 июль, 547 нче; 2016 ел, 9 август, 547 нче; 2018 ел, 25 гыйнвар, 39 нчы; 2018 ел, 4 апрель, 206 нчы; 2018 ел, 29 сентябрь, 874 нче; 2018 ел, 10 декабрь, 1099 нчы; 2019 ел, 9 сентябрь, 805 нче; 2020 ел, 3 декабрь, 1091 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлектә:

1.9.6 бүлекчәдә:

«Атмосфера һавасын саклау» бүлегендә:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Атмосфера һавасының норматив сыйфатын тәэмин итү өчен «Атмосфера һавасын саклау турында» 1999 елның 4 маендагы 96-ФЗ номерлы Федераль закон, «Шәһәр һәм авыл җирлекләре территорияләрен карап тотуга, су объектларына, эчәргә яраклы суга һәм эчәргә яраклы су белән тәэмин итүгә, атмосфера һавасына, туфракларга, торак урыннарга, җитештерү, иҗтимагый биналарны эксплуатацияләүгә, санитария һәм

эпидемиягә каршы (профилактика) чараларны оештыруга һәм үткәрүгә карата санитария-эпидемиология таләпләре» дигән 2.1.3684-21 нче санитария кагыйдәләре һәм нормалары (алга таба – 2.1.3684-21 нче санитария кагыйдәләре һәм нормалары) һәм «Предприятиеләр, корылмалар һәм башка объектларның санитария-саклау зоналары һәм санитария ягыннан классификациясе» дигән 2.2.1/2.1.1.1200-03 нче санитария кагыйдәләре һәм нормалары (алга таба – 2.2.1/2.1.1.1200-03 нче санитария кагыйдәләре һәм нормалары) таләпләрен үтәргә кирәк.»;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Атмосфера һавасында пычраткыч матдәләрнең рөхсәт ителә торган иң чик концентрацияләре «Кеше өчен яшәү мохите факторларының иминлеген һәм (яки) зарарсызлыгын тәэмин итүгә карата гигиена нормативлары һәм таләпләре» дигән 1.2.3685-21 нче санитария кагыйдәләре һәм нормалары (алга таба – 1.2.3685-21 нче санитария кагыйдәләре һәм нормалары) һәм 2.1.3684-21 нче санитария кагыйдәләре һәм нормалары нигезендә кабул ителә. Аларны үтәү халыкның сәламәтлегенә һәм яшәү шартларына турыдан-туры яки читләтеп йогынты ясамауны тәэмин итә.»;

уникенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

уналтынчы абзацта «2.1.6.1032-01 нче санитария кагыйдәләре һәм нормалары» сүзләрен «2.1.3684-21 нче санитария кагыйдәләре һәм нормалары» сүзләренә алмаштырырга;

«Су ресурсларын саклау» бүлегендә:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Химик матдәләрнең булуы су объектлары суларындагы матдәләрнең рөхсәт ителә торган иң чик гигиена концентрацияләреннән һәм рөхсәт ителгән якынча иң чик дәрәҗәләреннән, 1.2.3685-21 нче санитария кагыйдәләрендә һәм нормаларында расланган гигиена нормативларыннан артмаска тиеш.»;

дүртенче абзацта «Җир өсте суларын саклауга карата гигиена таләпләре» дигән 2.1.5.980-00 нче санитария кагыйдәләре һәм нормалары» сүзләрен «1.2.3685-21 нче санитария кагыйдәләре һәм нормалары, 2.1.3684-21 нче санитария кагыйдәләре һәм нормалары» сүзләренә алмаштырырга;

егерменче абзацта «Җир өсте суларын саклауга карата гигиена таләпләре» дигән 2.1.5.980-00 нче санитария кагыйдәләре һәм нормалары» сүзләрен «1.2.3685-21 нче санитария кагыйдәләре һәм нормалары һәм 2.1.3684-21 нче санитария кагыйдәләре һәм нормалары» сүзләренә алмаштырырга;

«Туфракны саклау» бүлегендә:

икенче абзацта «Туфракның сыйфатына карата санитария-эпидемиология таләпләре» дигән 2.1.1287-03 нче санитария кагыйдәләре һәм нормалары» сүзләрен «1.2.3685-21 нче санитария кагыйдәләре һәм нормалары һәм 2.1.3684-21 нче санитария кагыйдәләре һәм нормалары» сүзләренә алмаштырырга;

унөченче абзацта«Туфракның сыйфатына карата санитария-эпидемиология таләпләре» дигән 2.1.1287-03 нче санитария кагыйдәләре һәм нормалары» сүзләрен «1.2.3685-21 нче санитария кагыйдәләре һәм нормалары һәм 2.1.3684-21 нче санитария кагыйдәләре һәм нормалары» сүзләренә алмаштырырга;

«Тавыштан һәм вибрациядән саклау» бүлегендә:

сигезенче абзацта «Эш урыннарында, торак һәм җәмәгать урыннарында һәм торак төзелеше территориясендә инфратавыш» дигән 2.2.4/2.1.8.583-96 нчы санитария

нормалары» сүзләрен «1.2.3685-21 нче санитария кагыйдәләре һәм нормалары» сүзләренә алмаштырырга;

унынчы абзацта «Торак һәм җәмәгать биналары урыннарында җитештерү вибрациясе, вибрация. Санитария нормалары» дигән 2.2.4/2.1.8.566-96 нчы санитария нормалары» сүзләрен «1.2.3685-21 нче санитария кагыйдәләре һәм нормалары» сүзләренә алмаштырырга;

«Электр магнит кырларыннан саклау» бүлегендә:

алтынчы абзацта «Торак биналарда һәм урыннарда яшәү шартларына карата санитария-эпидемиология таләпләре» дигән 2.1.2.2645-10 нчы санитария кагыйдәләре һәм нормалары» сүзләрен «1.2.3685-21 нче санитария кагыйдәләре һәм нормалары» сүзләренә алмаштырырга;

«Микроклиматны көйләү» бүлегенең 14 нче таблицасына искәрмәләрнең 2 пунктындагы икенче абзацында «Торак һәм җәмәгать биналары урыннарының һәм территорияләрнең инсоляциясенә һәм кояштан сакланышына карата гигиена таләпләре» дигән 2.2.1/2.1.1.1076-01 нче санитария кагыйдәләре һәм нормалары» сүзләрен «1.2.3685-21 нче санитария кагыйдәләре һәм нормалары» сүзләренә алмаштырырга;

«Җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү» бүлегенең унбишенче абзацында «Җитештерү һәм куллану калдыкларын урнаштыруга һәм зарарсызландыруга карата гигиена таләпләре» дигән 2.1.7.1322-03 нче санитария кагыйдәләре һәм нормалары» сүзләрен «2.1.3684-21 нче санитария кагыйдәләре һәм нормалары» сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлекчәнең 20 нче таблицасына искәрмәләрнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Күрсәткеч Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 3 октябрь, 888 нче карары нигезендә билгеләнде.»;

II бүлекнең 29 нчы таблицасындагы 2.2 пунктының 4 графасында «Янгыннан саклау объектларын проектлаштыру нормалары» дигән 101-95 нче янгын куркынычсызлыгы нормаларының 7 нче кушымтасы нигезендә, шулай ук» сүзләрен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин